**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Центральная , д.51, с.Нижняя
Каменка, 423114

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КӘМИНКӘ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Үзәк урамы, 51 йорты, Түбән
Кәминкә авылы, 423114

тел./факс(84396) 2-35-21 email: Nkam.Cmn2@tatar.ru

---

№ 81 15 март 2018 ел.

**КАРАР**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы**
**Татарстан Республикасы**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән районы прокурорының 2018 елның 9 февралендәге 161-р номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 ноябрендәге «Җир салымы турында» гы 61 номерлы карарның 6 статьясын «Салым түләүчеләр тарафыннан салым базасын киметү хокукын раслый торган документларны бирү тәртибе һәм сроклары» яңа редакциядә бәян итәргә:

   «Салым түләүчеләр - салым ташламалары хокукына ия физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калуы рәвешендә салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы. Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау РФ Салым Кодексының 361.1 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

   «Салым түләүчеләр- билгеләнгән срокларда, салым декларациясен бирүче шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru),

Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кәминкә авыл җирлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге советы рәисе,
җирле үзидарә башлыгы Р.Р. Халиков